КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 март г.Казань № 316

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 гыйнвар, 25 нче; 2017 ел, 21 март, 167 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1113 нче, 2019 ел, 20 сентябрь, 861 нче, 2020 ел, 14 август, 684 нче, 2021 ел, 31 май,  399 нчы, 2022 ел,

30 декабрь, 1512 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 7 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин